РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-42-05, факс: (85593) 2-80-13

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-42-05, факс: (85593) 2-80-13

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 15 » 03 2023 ел №328

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында ирекледек (волонтерлык) мәсьәләләре буенча совет төзү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль Законына, 1995 елның 11 августындагы «Хәйрия эшчәнлеге һәм ирекледек (волонтерлык) турында»гы 135-ФЗ санлы Федераль Законына, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законына ярашлы, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Ирекледекне (волонтерлыкны) үстерү һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә эшчәнлек алып баручы ирекле берләшмәләрнең эшчәнлегенә ярдәм итү максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында ирекледек (волонтерлык) мәсьәләләре буенча Совет төзергә.

2. Түбәндәгеләрне расларга:

- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында ирекледек (волонтерлык) мәсьәләләре буенча совет турында нигезләмә (1 нче кушымта);
- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында ирекледек (волонтерлык) мәсьәләләре буенча Совет составы (2 нче кушымта).

3. Әлеге карарны түбәндәге электрон адрес буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталын «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге электрон адрес буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru/.

мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге электрон адрес буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru/.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты
җитәкчесе С.П. Самонина

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитетының
2023 елның “___”________
_____санлы карарына
1 кушымта

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында иреклелек (волонтерлык) мәсьәләләре буенча совет турында нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында иреклелек (волонтерлык) мәсьәләләре буенча Совет (алга таба - Совет) - Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы башкарма комитеты каршындагы даими эшләүче консультатив орган, ул Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының җирле үзидарә органнарының, иҗтимагый берләшмәләрнең, социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларның, ирекле (волонтерлык) оешмаларының, башка кызыксынган оешмаларның үсештә көчләрен берләштерү максатларында килешенгән эшчәнлеген тәэмин итә.

1.2. Совет үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясе һәм Татарстан Республикасы Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары һәм башка хокукый актлары, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының норматив хокукый актлары һәм әлеге Нигезләмә белән җитәкчелек итә.

## 2. Советның максаты һәм бурычлары

2.1. Советның максаты – иреклелекне (волонтерлыкны) үстерүдә көчләрне туплау һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының иҗтимагый ирекле берләшмәләре эшчәнлеген координацияләү.

2.2. Советның Бурычлары:

- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы җирле үзидарә органнарының иҗтимагый берләшмәләр, социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар, ирекле (волонтерлык) оешмалар һәм башка кызыксынган оешмалар белән хезмәттәшлеген тәэмин итү;
- социаль мәсьәләләрне хәл итүдә ирекле (волонтерлык) оешмаларының һәм волонтерларның ихтыяҗын тәэмин итүче шартлар булдыру;
- Иреклелекне киңәйтү һәм ныгыту өчен шартлар тудыру, гамәлдәге оешмаларның эшчәнлегенә ярдәм итү һәм яңа ирекле (волонтерлык) оешмалары барлыкка килү өчен шартлар тудыру, аларның потенциалын арттыруга ярдәм итү;
- ирекле эшчәнлеккә методик, мәгълүмати, консультация ярдәме инфраструктурасын үстерү;

- халыкны ирекле (волонтерлык) эшчәнлек чараларын үткәрүгә җәлеп итү механизмнарын эшләү;

- ирекләлек (волонтерлык) өлкәсендә эшчәнлекне җайга салучы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының хокукый актлары проектлары турында фикер алышу.

- кабул ителгән хокукый актларны һәм хокукны куллану практикасын ирекле (волонтерлык) эшчәнлеген үстерүгә юнәлдерелгән гамәлдәге чараларның нәтиҗәлелеге предметына анализлау.

## 3. Советның хокуклары

3.1. Совет түбәндәгеләргә хокуклы:

3.1.1. Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарыннан, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы җирле үзидарә органнарыннан Совет компетенциясенә кагылышлы мәсьәләләр буенча кирәкле документлар һәм белешмәләрне билгеләнгән тәртиптә сорарга һәм алырга.

3.1.2. Совет утырышларына Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарыннан, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының җирле үзидарә органнарыннан, иҗтимагый берләшмәләрдән, социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалардан, ирекле (волонтерлык) оешмаларыннан һәм башка кызыксынган оешмалардан вәкилләр чакырырга.

3.2. Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының җирле үзидарә органнарына Ирекләлекне (волонтерлыкны) үстерү мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр тәкъдим итәргә.

## 4. Советның эшләү тәртибе

4.1. Совет составына Совет рәисе, Совет рәисе урынбасары, секретарь, ирекле (волонтерлык) эшчәнлеген төп оештыручылар, Ирекле (волонтерлык) төркемнәр лидерлары, иҗтимагый берләшмәләр һәм оешмалар, Совет составына кертүгә үз ризалыкларын язма рәвештә белдергән предприятиеләр керә.

4.2. Совет рәисе вазифасы буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе булып тора.

4.3. Совет составы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана.

4.4. Совет эшенә совет рәисе җитәкчелек итә, ә ул булмаганда аның кушуы буенча аның урынбасары.

4.5. Совет утырышларны кирәк булганда, кварталга бер тапкырдан да сирәгрәк үткәрми.

4.6. Үз вәкаләтләре кысаларында Совет рәисе:

- Совет утырышын уздыру турында Карар кабул итә, көн тәртибен билгели;

Совет кабул иткән карарларның үтәлешен тәэмин итә һәм контрольдә тота;

Совет әгъзаларына аның компетенциясе чикләрендә йөкләмәләр бирә.

4.7. Совет эше аның утырышларында расланган планнарга ярашлы рәвештә башкарыла.

4.8. Совет утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы дип санала.

4.9. Совет утырышына көн тәртибе мәсьәләләре буенча материаллар Совет әгъзалары тарафыннан аларның компетенциясе кысаларында әзерләнә. Материаллар совет секретаре исеменә Совет утырышы көненә өч көн кала тапшырыла.

4.10. Совет карарлары Совет утырышында катнашучы Совет әгъзалары санының күпчелек тавышы белән кабул ителә һәм Совет утырышы протоколы белән рәсмиләштерелә. Тавышлар тигез булган очракта, Совет утырышында рәислек итүченең тавышы хәл иткүче булып тора. Совет карарлары тәкъдим итү характерында.

4.11. Совет утырышы протоколына Совет утырышында рәислек итүче һәм Совет секретаре Совет утырышыннан соң 5 эш көне дәвамында кул куя.

4.12. Совет утырышы протоколында:

- Совет утырышын үткәрү көне, вакыты һәм урыны;

Совет утырышының расланган көн тәртибе;

утырышта катнашкан Совет әгъзаларының һәм башка чакырылган затларның исемнәре һәм вазифалары;

- Совет утырышы көн тәртибе мәсьәләләре буенча кабул ителгән карарлар.

4.13. Совет утырышларының протоколлары яки алардан йөкләмәләр белән кирәкле өземтәләр совет Секретаре тарафыннан Совет утырышы көненнән алып 5 эш көне эчендә йөкләмәләрне үтәү өчен җаваплы вазифаи затларга җибәрелә.

4.14. Совет эшчәнлеген мәгълүмат белән тәэмин итүне Совет секретаре башкара.

4.15. Совет эшчәнлеген оештыру-техник тәэмин итүне Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты һәм «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге» муниципаль казна учреждениесе башкара.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитетының
2023 елның “___”________
_____санлы карарына
2 кушымта

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында иреклелек (волонтерлык) мәсьәләләре буенча Совет составы

| | |
|---|---|
| Самонина Светлана Петровна | Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитет җитәкчесе – Совет рәисе |
| Рузанов Сергей Александрович | Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары – Совет рәисе урынбасары |
| Галлямова Регина Артур кызы | Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы “Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге” МКУ начальнигы – Совет Сәркатибе |
| Совет әгъзалары: | |
| Абрамов Сергей Александрович | “Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетның мәгариф бүлеге” МКУ начальнигы |
| Абдурахманов Рөстәм Рамиль улы | “Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетның мәдәният бүлеге” МКУ начальнигы |
| Бурыкина Марина Ивановна | ҖТСБ ЯФҮ “Форпост” МБУ директоры |
| Карпеев Александр Сергеевич | “Атлант” ЯЯК МБУ директоры |
| Шакирова Светлана Закир кызы | “Урыссу ҮРХ” ДАССУ баш табибы (килешү буенча) |
| Әминова Зөлфия Җәүдәт кызы | Татарстан Республикасы Ютазы район Советының авыл җирлекләре белән эшләү бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Фалько Анастасия Михайловна | Яшь Гвардиянең Ютазы бүлекчәсе җитәкчесе (килешү буенча) |
| Гомәров Айдар Альберт улы | «Электросоединитель» АҖ яшьләр комитеты рәисе (килешү буенча) |
| Михайлова Анастасия Ивановна | Ютазы тана («Ютазы яңалыгы») газетасы редакциясе белгече (килешү буенча) |